ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 24 декабрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 1 – 2; 2011, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 5; 2015, № 10 (I өлеш); 2016, № 3; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш); 2018, № 78 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш); 2022, № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 35 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 56 (I өлеш), № 75 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

«4) һөнәрчелек эшчәнлеге субъектлары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган һөнәрчелек эшчәнлеге төрләре исемлегендә каралган һөнәрчелек эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, узган календарь елда хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны биш кешедән артмаган кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм индивидуаль эшкуар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затлар (алга таба – махсус салым режимын кулланучы физик затлар).»;

2) 3 статьяның 3 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $14^1$ һәм $14^2$ пунктлар өстәргә:

«$14^1$) һөнәрчелек эшчәнлеге төрләре исемлеген, кече һәм урта эшкуарлык субъектларын һәм махсус салым режимын кулланучы физик затларны һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына кертеп карау тәртибен һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектлары реестрын алып бару тәртибен раслау;

$14^2$) идентификация чаралары белән мәҗбүри маркировкаланырга тиеш булмаган һөнәрчелек эшчәнлеге субъектлары хезмәте продуктлары исемлеген раслау;»;

3) 15 статьяның $4^1$ өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$4^1$. Махсус салым режимын кулланучы физик затларга мәгълүмати ярдәм күрсәтү дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан махсус салым режимын кулланучы физик затлар эшчәнлеген үстерү өчен кирәкле мәгълүматны, шул исәптән әлеге статьяның 3 өлешендәге 1, 6 һәм 7 пунктларында күрсәтелгән мәгълүматны, әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә мәгълүмат системаларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мәгълүмати ярдәм буенча рәсми сайтларда урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

4) 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. **Халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына ярдәм**

Халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына ярдәм күрсәтү Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан түбәндәге рәвешләрдә гамәлгә ашырыла:

1) халык сәнгать кәсепләрен, декоратив-гамәли сәнгатьне һәм һөнәрчелек эшчәнлеген торгызу һәм үстерү өчен уңайлы шартлар тудыру;

2) халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар, шул исәптән халык сәнгать кәсепләре һәм һөнәрләр палаталары һәм үзәкләре, төзү һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү;

3) халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларын һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларын халык сәнгать кәсепләрен, декоратив-гамәли сәнгатьне һәм һөнәрчелек эшчәнлеген үстерүнең дәүләт программаларын (ярдәмче программаларын) эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнашуга җәлеп итү;

4) халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына финанс, мөлкәти, мәгълүмати, хокукый һәм консультатив ярдәм, аларның хезмәткәрләрен әзерләү, яңадан әзерләү һәм квалификациясен күтәрү өлкәсендә ярдәм;

5) халык сәнгать кәсепләре өлкәсендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм һөнәрчелек эшчәнлеге субъектларына ярдәм буенча башка чараларны гамәлгә ашыру.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 26 декабрь
№ 97-ТРЗ